**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 29 декабрендәге 4743 номерлы карары**

## Мәскәү районының Академик Королев урамындагы территорияне ызанлау проектын раслау турында

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, «Беренчел документларны әзерләү үзәге» акционерлык җәмгыяте гаризасы буенча, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43, 45, 46 статьялары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 7 октябрендәге 3394 номерлы «Мәскәү районының Академик Королев урамындагы территорияне ызанлау проектын әзерләү турында»гы карары нигезендә, 2025 елның 11 декабреннән алып 2025 елның 25 декабренә кадәр уздырылган җәмәгатьчелек белән фикер алышулар нәтиҗәләре буенча бәяләмәне исәпкә алып, **карар бирәм**:

1. Мәскәү районының Академик Королев урамындагы территорияне ызанлау проектын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга;

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитетына (Р.Г.Галәветдинов):

2.1. әлеге карарның кушымтасы нигезендә җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр исәбенә кую өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә;

2.2. әлеге карарга кушымта нигезендә җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр исәбенә кую һәм ясала торган җир кишәрлекләренә карата муниципаль милек хокукын теркәү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә ышанычнамәсез мөрәҗәгать итәргә;

2.3. җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр исәбенә куйганнан соң, адреслы номер бирү һәм белешмәләрне Дәүләт адреслар реестрына кертү өчен Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенә җир кишәрлекләренең кадастр номерлары турында мәгълүмат бирергә;

2.4. җир кишәрлекләреннән алга таба файдаланганда:

2.4.1. инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренең куркынычсызлыгын һәм әлеге челтәрләрне эксплуатацияләүче оешмалар өчен аларга тоткарлыксыз керүне тәэмин итәргә;

2.4.2. территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар өчен билгеләнгән чикләүләрне үтәргә;

3. Әлеге карарны, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, үзгәртелгән табигать-рекреация комплексы чикләренең координаталары исемлегеннән, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитутларының характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (кушымта) (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга.

4. Әлеге карарны, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, үзгәртелгән табигать-рекреация комплексы чикләренең координаталары исемлегеннән, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитутларының характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (кушымта) (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга;

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның  29 декабрендәге
4743 номерлы карары белән
расланган

**Мәскәү районының Академик Королев урамындагы**
**территорияне ызанлау проекты**

Мәскәү районының Академик Королев урамындагы территорияне ызанлау проекты түбәндәгеләрдән тора:

I. Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, үзгәртелгән табигать-рекреация комплексы чикләренең координаталары исемлеге, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге, инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитутларының характерлы нокталары координаталары исемлеге белән ясала торган җир кишәрлекләре турында белешмәләр булган нигезләмә.

II. Территорияне ызанлау сызымы.

III. Табигать-рекреация комплексы чикләренең һәм билгеләнә торган кызыл линияләрнең сызымы.

Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, үзгәртелгән табигать-рекреация комплексы чикләренең координаталары исемлеге, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге, инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитутларының характерлы нокталары координаталары исемлеге хезмәт урынында файдалана торган материаллар булып санала һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (ww.docskzn.ru) бастырып чыгарылырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

## I. Ясала торган җир кишәрлекләре турында белешмәләр белән нигезләмә

Мәскәү районының Академик Королев урамындагы территорияне ызанлау проектын әзерләү чикләрне бозуны булдырмас өчен планлаштыру структурасы элементы чикләрендә җир кишәрлекләре ясау, гомуми файдаланудагы территориянең (гомумшәһәр әһәмиятендәге паркның) кызыл линияләрен билгеләү һәм табигать-рекреация каркасы (комплексы) чикләрен төзәтү максатында гамәлгә ашырыла.

12,94 га мәйданлы табигать-рекреация каркасы элементларын («Урицкий паркы» гомумшәһәр әһәмиятендәге 332 номерлы парк) саклап калу максатыннан, территорияне ызанлау проектында табигать-рекреация каркасының әлеге элементы чикләрен аның мәйданын киметмичә үзгәртү күздә тотыла. Табигать-рекреация каркасы чикләрен үзгәртү Казан шәһәр округының Генераль планы нигезендә Казан шәһәр округы чикләрендә урнаштыру өчен планлаштырыла торган район әһәмиятендәге «Проектлаштырыла торган 13 номерлы юл» магистраль урамын төзүне гамәлгә ашыру срокларын исәпкә алып каралган. Табигать-рекреация каркасы чикләре әлеге линия объектын проектлаштыруның алдагы этапларында төгәлләштерелергә һәм/яки күчерелергә тиеш.

Территорияне ызанлау проектында гомуми файдаланудагы территория – гомумшәһәр әһәмиятендәге парк – «Урицкий паркы»ның кызыл линияләрен билгеләү күздә тотыла.

Территорияне ызанлау проекты шартлы билгеләре :ЗУ1 һәм :ЗУ2 булган җир кишәрлекләре ясауны күздә тота. Шартлы билгесе :ЗУ1 булган җир кишәрлеге муниципаль милектә булган һәм дәүләт милкендәге җирләр белән бергә «“Тасма” физкультура-спорт берләшмәсе» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесенә даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирелгән, кадастр номеры 16:50:000000:196 булган җир кишәрлеген (аерымланган 16:50:100107:3, 16:50:100106:41, 16:50:100106:42 кишәрлекләреннән торган җирдән бердәм файдалану ) яңадан бүлү юлы белән барлыкка килә. Шартлы билгесе :ЗУ2 булган җир кишәрлеге дәүләт милке җирләреннән ясала.

Шартлы билгесе :ЗУ1 булган җир кишәрлеген ясау Казан шәһәр округының Генераль планы нигезендә җирле әһәмияттәге социаль инфраструктура объектларын (объектын) – стадион һәм «“Тасма” физкультура-спорт берләшмәсе» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесе балаларына өстәмә белем бирү учреждениеләрен урнаштыру өчен каралган.

Шартлы билгесе :ЗУ2 булган җир кишәрлеге табигый-рекреацион каркас элементы чикләрен һәм мәйданын төгәлләштерү максатыннан ясала. Табигый-рекреацион каркасны күчерү шартлы билгесе :ЗУ1 булган кишәрлек территориясеннән башкарыла, ул шартлы билгесе :ЗУ2 булган җир кишәрлеге ясалганнан соң гына ясалырга мөмкин.

Ясала торган җир кишәрлекләре турында мәгълүмат таблицада күрсәтелгән.

Таблица

| **Ясала торган җир кишәрлеге-нең шартлы билгесе** | **Ясала торган җир кишәрлегене ң мәйданы, кв.м** | **Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры** | **Ясала торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Җир кишәрлеген ясау ысуллары** |
|---|---|---|---|---|
| :ЗУ1 | 55806 | 16:50:000000:196 | Спорт | Җир уишәрлеген һәм дәүләт милкендәге җирләрне яңадан бүлү |
| :ЗУ2 | 1755 | — | Территорияне төзекләндерү (код 12.0.2) | Дәүләт милкендәге җирләрдән ясау |

Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясындагы 3 пункт нигезендә билгеләнгәнчә, җир кишәрлекләре ясау өчен нигез булып торган җир кишәрлекләренең максатчан билгеләнеше һәм алардан рөхсәт ителгән файдалану төре ясала торган җир кишәрлекләренең максатчан билгеләнеше һәм алардан рөхсәт ителгән файдалану төре дип танылa.

Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы «Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре турында»гы карары карары белән расланган Казан шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) нигезендә, ясала торган :ЗУ2 җир кишәрлеге катлар саны уртача булган торак төзелеше территориаль зонасында (Ж3) урнашкан, ясала торган :ЗУ2 җир кишәрлеге спорт объектларын урнаштыру территориаль зонасында (О5) урнашкан.

Кагыйдәләрнең 30 статьясы нигезендә ясала торган :ЗУ1 җир кишәрлегенең максималь күләме «Спорт» рөхсәт ителгән файдалану төре өчен билгеләнмәгән, җир кишәрлегенең минималь күләме Кагыйдәләрнең 22 статьясы нигезендә


кулланылмый. Кагыйдәләрнең 24 статьясы нигезендә рөхсәт ителгән файдалану төре «Территорияне төзекләндерү (код 12.0.2)» булган :ЗУ2 җир кишәрлеге өчен чик күләмнәре билгеләнми.

Ясала торган җир кишәрлекләре түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

- кирәк булганда һәм яңа инженерлык коммуникацияләрен салу өчен башка трассаны сайлау мөмкинлеге булмаганда, җир кишәрлеге хуҗасы белән килештереп, тоткарлыксыз керү мөмкинлеген;

- гамәлдәге инженерлык коммуникацияләрен ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү өчен, җир кишәрлеге хуҗасы белән килештереп, эксплуатацияләүче оешмаларның тоткарлыксыз керү мөмкинлеген.


# II. Территорияне ызанлау сызымы.




**Масштаб 1:5500**

| **Шартлы билгеләр:** | |
|---|---|
| | ызанлау проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чиге |
| | ясала торган җир кишәрлеге чиге |
| | беренчел җир кишәрлеге чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлегенең чиге |
| | кадастр кварталы чиге |
| | инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чиге |
| ● 1 | инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чикләренең характерлы ноктасы |
| ○ 1 | ызанлау проекты расланган территория чикләренең характерлы ноктасы |
| ● н1 | ясала торган җир кишәрлегенең характерлы ноктасы |
| 16:50:011322 | кадастр кварталы |
| 16:50:011322:24 | җир кишәрлегенең кадастр номеры |


# 1 бит




Масштаб 1:3000

| **Шартлы билгеләр:** | |
|---|---|
| | ызанлау проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чиге |
| | ясала торган җир кишәрлеге чиге |
| | беренчел җир кишәрлеге чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлегенең чиге |
| | кадастр кварталы чиге |
| | инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чиге |
| ● 1 | инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чикләренең характерлы ноктасы |
| ○ 1 | ызанлау проекты расланган территория чикләренең характерлы ноктасы |
| ● н1 | ясала торган җир кишәрлегенең характерлы ноктасы |
| 16:50:011322 | кадастр кварталы |
| 16:50:011322:24 | җир кишәрлегенең кадастр номеры |

# 2 бит





Масштаб 1:3000

**Шартлы билгеләр:**

| | |
|---|---|
| | ызанлау проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чиге |
| | ясала торган җир кишәрлеге чиге |
| | беренчел җир кишәрлеге чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлегенең чиге |
| | кадастр кварталы чиге |
| | инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чиге |
| ● 1 | инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чикләренең характерлы ноктасы |
| ○ 1 | ызанлау проекты расланган территория чикләренең характерлы ноктасы |
| ● н1 | ясала торган җир кишәрлегенең характерлы ноктасы |
| 16:50:011322 | кадастр кварталы |
| 16:50:011322:24 | җир кишәрлегенең кадастр номеры |

# 3 бит





**Масштаб 1:3000**

**Шартлы билгеләр:**

| | |
|---|---|
| | ызанлау проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чиге |
| | ясала торган җир кишәрлеге чиге |
| | беренчел җир кишәрлеге чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлегенең чиге |
| | кадастр кварталы чиге |
| | инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чиге |
| ● 1 | инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чикләренең характерлы ноктасы |
| ○ 1 | ызанлау проекты расланган территория чикләренең характерлы ноктасы |
| ● н1 | ясала торган җир кишәрлегенең характерлы ноктасы |
| 16:50:011322 | кадастр кварталы |
| 16:50:011322:24 | җир кишәрлегенең кадастр номеры |

# III. Табигать-рекреация комплексы чикләренең һәм билгеләнә торган кызыл линияләрнең сызымы





**Масштаб 1:5500**

**Шартлы билгеләр:**

| | |
|---|---|
| | ызанлау проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чиге |
| | үзгәртелгән табигать-рекреация комплексы чикләре |
| | гамәлдәге табигать-рекреация комплексы чикләре |
| | гамәлдәге җир кишәрлегенең чиге |
| | билгеләнә торган кызыл линияләр |
| | үзгәртелгән табигать-рекреация комплексы чикләренең характерлы ноктасы |
| ● к1 | билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы ноктасы номеры |
| 16:50:011322 | кадастр кварталы |
| 16:50:011322:24 | җир кишәрлегенең кадастр номеры |

# 1 бит





**Масштаб 1:3000**

**Шартлы билгеләр:**

| | |
|---|---|
| | ызанлау проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чиге |
| | үзгәртелгән табигать-рекреация комплексы чикләре |
| | гамәлдәге табигать-рекреация комплексы чикләре |
| | гамәлдәге җир кишәрлегенең чиге |
| | билгеләнә торган кызыл линияләр |
| | үзгәртелгән табигать-рекреация комплексы чикләренең характерлы ноктасы |
| ● к1 | билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы ноктасы номеры |
| 16:50:011322 | кадастр кварталы |
| 16:50:011322:24 | җир кишәрлегенең кадастр номеры |

# 2 бит





Масштаб 1:3000

**Шартлы билгеләр:**

| | |
|---|---|
| | ызанлау проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чиге |
| | үзгәртелгән табигать-рекреация комплексы чикләре |
| | гамәлдәге табигать-рекреация комплексы чикләре |
| | гамәлдәге җир кишәрлегенең чиге |
| | билгеләнә торган кызыл линияләр |
| | үзгәртелгән табигать-рекреация комплексы чикләренең характерлы ноктасы |
| ● к1 | билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы ноктасы номеры |
| 16:50:011322 | кадастр кварталы |
| 16:50:011322:24 | җир кишәрлегенең кадастр номеры |

## 3 бит




**Масштаб 1:3000**

| **Шартлы билгеләр:** | |
|---|---|
| | ызанлау проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чиге |
| | үзгәртелгән табигать-рекреация комплексы чикләре |
| | гамәлдәге табигать-рекреация комплексы чикләре |
| | гамәлдәге җир кишәрлегенең чиге |
| | билгеләнә торган кызыл линияләр |
| | үзгәртелгән табигать-рекреация комплексы чикләренең характерлы ноктасы |
| ● к1 | билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы ноктасы номеры |
| 16:50:011322 | кадастр кварталы |
| 16:50:011322:24 | җир кишәрлегенең кадастр номеры |